ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2023 г. Казань № 632-98/кс-2023

«ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен техник суга һәм су бүлүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2020 №372-170/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2024 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, техник суга, су агызуга 2024-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 14.12.2023 №58-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 09.12.2020 №372-170/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 №511-139/кс-2022 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» ҖЧҖ) өчен техник суга һәм ташландык су агызуга әлеге

карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.»;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2020 №372-170/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2023 № 632-98/кс-2023 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» ҖЧҖ өчен техник суга һәм ташландык су агызуга 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр |
|---|---|---|---|---|
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | |
| 1 | «ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | |
| 1.1 | Технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | |
| 1.1.1 | Кабат кулланыла торган су белән тәэмин итү | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 2,80 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 3,67 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 3,39 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 3,39 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 3,45* | |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 3,45 | |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 3,52 | |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 3,52 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 4,18 | |
| 1.1.2 | Әйләнештәге су белән тәэмин итү | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 2,44 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 2,56 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 2,56 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 2,56 | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 2,68* | |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 2,68 | |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 2,96 | |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 2,96 | |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 2,96 | |
| 1.1.3 | Химик агынты суларны агызу | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | | 141,22 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | | 190,13 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | | 185,52 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | | 185,52 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | | 199,48* |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | | 199,48 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | | 237,20 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | | 209,91 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | | 209,91 |
| 1.1.4 | Шламлы ташландык суларны агызу | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | | 10,37 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | | 11,71 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | | 11,71 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | | 12,15 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | | 12,18* |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | | 12,18 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | | 14,29 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | | 13,90 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | | 13,90 |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 №511-139/кс-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге